ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
“ ЧУВАШ ЯЛТАНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

"24 " сентябрь 2018 г. № 48/1

Чистай муниципаль районы
Чуваш Ялтаны авыл җирлеге
территориясендә гражданнарга
үзара салым кертү һәм аның акчасын
файдалану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Жирле референдум турында” 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чистай муниципаль районы “Чуваш Ялтаны авыл җирлеге” Уставының 11 статьясы нигезендә, Чуваш Ялтаны авыл җирлеге Советының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 47/1 номерлы карары, Чуваш Ялтаны авыл җирлеге Башкарма комитетының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 16 номерлы карары белән, Чуваш Ялтаны муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Чуваш Ялтаны авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез Чистай муниципаль районы Чуваш Ялтаны авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан тыш, 2019 елда 200 сум күләмендә үзара салым салуны кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

- Чуваш Ялтаны, Ишәле авыллары эчендәге юлларны ремонтлауга (щебень сатып алу, китертерүгә)
- Ишәле авылындагы коены ремонтлауга;
-Акбулат авылындагы эчке суүткәргеч челтәре төзүгә һәм ремонт ясауга

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең халык күпләп җыела торган урыннарга, мәгълүмат стендлары һәм такталарына урнаштырырга.

Чуваш Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы С.М. Егоров